ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422701 Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы, Зур Кызыл урамы, 113А йорт

ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422701, Республика Татарстан, Высокогорский
район,с. Высокая Гора, ул. Б. Красная, д. 113А

Тел./факс: +7(84365) 74-7-79 e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

КАРАР
16 июль 2025 ел

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 20

Кадастр номерлы 16:16:190803:1407 булган җир кишәрлегенә файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау авыл җирлеге уставы һәм 2019 елның 19 мартындагы 495 номерлы (2021 елның 22 апрелендәге 60 номерлы Совет карары редакциясендә) Биектау авыл җирлеге Советы карары белән расланган Биектау авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә кеше хокуклары, җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының уңай шартларын үтәү максатларында
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге территориясендә кадастр номеры 16:16:190803:1407 булган җир кишәрлегенә карата капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга  рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар билгеләргә. Үткәрү датасы һәм вакыты: 29 июльда 2025 ел 11 сәг. 00 мин.

Үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау авылы, Зур Кызыл урамы, кадастр номеры 16:16:190803:1407 булган җир кишәрлеге. Гавами тыңлауларда тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр язма рәвештә 2025 елның 27 июльга кадәр 8.00 дән 17.00 гә кадәр Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авылы, Зур Кызыл урамы, 113 А йорт адресы буенча Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында кабул ителә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авылы, Зур Кызыл урамы, 113 А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына, вакытлы матбугат басмасы ярдәмендә «Биектау хәбәрләре» газетасында бастырып чыгару юлы белән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә «авыл җирлекләре» бүлегендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Биектау авыл җирлеге башлыгы А.А. Хабибуллин

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге
Советы  башлыгының
2025 елның 16 июльдәге
№ 20 карарына

Гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе
“Кадастр номеры 16:16:190803:1407 булган җир кишәрлегенә файдаланунының шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү” проектына

1. Тәкъдимнәр Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авылы, Зур Кызыл ур., 113А йорты яисә факсимиль элемтә ярдәмендә 8 (84365) 74-7-79 язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә кушымтада бирелгән үрнәк нигезендә:

| № п/п | Тәкъдимнәр кертүче | Кертү датасы | Абзац, пункт, часть, статья | Проектның тексты | Текст җөмләләр | Проект тексты исәпкә алып кертелгән җөмләләр | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

2. Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр 2025 елның 28 июльга кадәр, әлеге карарны рәсми рәвештә игълан иткән көннән кабул ителә.

Кушымта N 2
Татарстан Республикасы
Биектау  муниципаль районы
Биектау  авыл җирлеге Советы
башлыгының
2025 елның 16 июльдәге
№ 20 карарына

Килүче тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эш төркеме

1. Хабибуллин А.А. - комиссия рәисе, Биектау авыл җирлеге башлыгы.
2. Закирова Г.Р. – комиссия секретаре, Биектау авыл җирлеге башкарма комитетының әйдәүче белгече.
3. Касюков М.Н. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең комиссия әгъзасы, 7 нче округ депутаты
4. Хидиятуллин М.Ф. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең комиссия әгъзасы, 11 нче округ депутаты
5. Хисамутдинов Р.Ш. - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ башкарма комитетының архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы (килешү буенча)